Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 17**

Корноухово ав. 2016 елның 4 октябре

Корноухово авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в» пунктчасы, 18, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Корноуховоавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноуховоавыл җирлеге Башкарма комитетының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 3 октябрендәге 7 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноуховоавыл җирлеге Советының «Референдум үткәрү инициативасы турында» 2016 елның 4 октябрендәге 17 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноуховоавыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 2016 елның 20 ноябренә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноуховоавыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

-Корноухово авылында суүткәргечләрне ремонтлау ;

- Чирмешан авылында Советлар урамында юлны ремонтлау;

-Корноухово авылында купер ремонтлау;

-Зюзино авылы белен Наумово арасындагы купер ремонтлау;

-Корноухово,Зюзино,Чирмешан,Наумово авылларында, кыш коне авыл эчендеге юлларны кардан чистарту.

ЮК ӘЙЕ".

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Корноухово авыл җирлегенең Корноухово авылы, Совхоз йорт 8 адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Корноухово авыл җирлеге Башлыгы В.В Колчанов